ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

25.12.2025 № 924

**«2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексы турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тотканга түләү күләмен билгеләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тотканга түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексын 2026 елга 12 % күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http:/pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ш. Хисаметдиновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин